РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТИМЕРШИКСКОГО СЕЛЬСКОГО
. ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362) 2-23-23

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы, 19 а йорт
тел. (84362) 2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.02.2020 № 10 п

Саба муниципаль районы Тимершык
авыл җирлеге биләмәсендә 2020-
2021 елларда кече һәм урта
эшмәкәрлекне үстерү
Программасын кабул итү турында

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законына, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге биләмәсе буенча 2020-2021 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасын кабул итәргә (программа теркәлә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам

Тимершык авыл җирлеге башлыгы: А.Х. Хаҗиев

Саба муниципаль районы
Тимершык авыл җирлеге
башкарма комитетының
2020 елның 07 февраленда
чыккан 10п номерлы карарга
1 номерлы кушымта

# *Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә 2020-2021 елларда кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасы*

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә 2020-2021 елларда кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасының паспорты.

| | |
|---|---|
| Программаның исеме: | “Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге буенча 2020-2021 елларда кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасы” |
| Программаның заказчысы: | Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче: | Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаның нигезе: | Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| Программаның максатлары: | -Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге буенча кече бизнесны үстерү өчен оптималь шартлар тудыру;<br>-Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү хисабына икътисадый үсешне һәм халыкның мәшгульлеге пробелмаларын хәл итү. |
| Программаның мәсәләләре: | 1. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге буенча кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм инфраструктурасын үстерү.<br>2. Кече һәм урта эшмәкәрлектән барлык бюджет дәрәҗәләренә салым керемнәрен арттыру.<br>3. Кече һәм урта эшмәкәрлекнең инвестицион активлыгын күтәрү.<br>4. Җир мөнәсәбәтләрен камилләштерү һәм җир базарын үстерү.<br>5. Минималь хезмәт хакы дәрәҗәсен минималь куллану бюджетыннан түбән булмаган зурлыкта тәэмин итү.<br>6. Бизнес-Хакимият-Җәмгыять коммуникация системасын үстерү.<br>7. Районның халыкның мәшгульлеге өлкәсендә балансл ы икътисадый сәясәтен исәпкә алып эшсез халыкны кече бизнес өлкәсенә тарту өчен өстәмә стимул булдыру.<br>8. Кече бизнес өлкәсендә мәшгуль булганнарны социаль яклау белән тәэмин итү.<br>9. Халыкның яшәү шартларын яхшыртуда кече бизнесның ролен үстерү. |

Программаның бүлекләре:

1. Тимершык  авыл җирлеге буенча кече һәм урта эшмәкәрлекнең торышына анализ.
2. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары һәм аларны программалы алымнар белән чишү мөһимлеген нигезләү.
3. Программаның социаль-икътисадый эффективлыгының көтелгән бәясе.
4. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре.
5. Программаның төп чараларына карата эшләнгән юнәлешләр.
6. Программаны тормышка ашыру механизмы.
7. Тимершык  авыл җирлеге территориясендә 2020-2021 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасының төп чаралары.

## 1. Тимершык  авыл җирлеге буенча кече һәм урта эшмәкәрлекнең торышына анализ.

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү - базар системалы хуҗалык итүнең аерылгысыз элементы булып тора. Алга киткән базар икътисадлы илләрдә кече эшмәкәрлек дәүләт икътисадының нигезе, хуҗалык итү үсешенең двигателе булып тора, чөнки бу-теләсә кайсы җәмгыятьтә эшлекле тормышның аеруча динамикалы һәм сыгылмалы формасы.

Базар системалы хуҗалык итү шартларында кече һәм урта эшмәкәрлекнең аерым ролен түбәндәге факторлар билгели:

- Үз байлыгын һәм лаеклы тормыш дәрәҗәсенүзе тәэмин итүче һәм гражданлык җәмгыятенең төп стабильләштерүче сәяси көче булып торучы урта сыйныфның өлешен зурайту;
- Кече һәм урта эшмәкәрлек секторында яңа эш урыннары булдыру өчен зур мөмкинлекләр булуы, җәмгыятьтә социаль киеренкелекне һәм эшсезлек дәрәҗәсен киметү;
- Төп халык массасының тормыш ориентирларын һәм иҗтимагый психологиясен үзгәртү;
- Кече һәм урта эшмәкәрлекнең җитештерү структурасын тиз әверелдерү өчен сыгылмалылыгы һәм сәләте, яңа технологияләр һәм фәнни эшкәртмәләрне оператив булдыру һәм куллану.

Шул сәбәпле Саба районы Тимершык  авыл җирлеге буенча кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасын эшләү һәм тормышка ашыру зарурлыгы килеп туа.

Әлеге программа  “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законына,  «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»  2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законына, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп эшләнгән.

01.01.2020 елга кече һәм урта эшмәкәрлек түбәндәге күрсәткечләр белән характерлана:

| № | Күрсәткечләр исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 | 2019 |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Тимершык  авыл җирлеге буенча теркәлгән кече предприятиеләр саны | бер. | 30 | 30 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Шулар арасыннан: | | | |
| | Авыл хуҗалыгы | бер. | 10 | 10 |
| | Сәүдә һәм җәмәгать туклануы | бер. | 9 | 9 |
| 3 | Шәхси эшмәкәр буларак теркәлгән физик затлар саны | кеше | 30 | 30 |
| | Кече предприятиеләр | бер. | | |
| | Юридик зат булмаган физик затлар | бер. | - | - |
| 4 | Кече һәм урта предприятиеләр буенча исемлектәге эшчеләрнең уртача саны | кеше | 90 | 90 |
| | Шул исәптән икътисад тармаклары буенча: | | | |
| | Авыл хуҗалыгы | кеше | 30 | 30 |
| | Сәүдә һәм җәмәгать туклануы | кеше | 16 | 16 |
| 5 | Кече предприятиеләрдә эшләүчеләргә түләнгән хезмәт хакы | мең сум | | |
| 6 | Кече предприятиеләрдә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы | мең сум | 15,0 | 17,0 |

2. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары һәм аларны программалы алымнар белән чишү мөһимлеген нигезләү

Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә хәзерге вакытта кече һәм урта эшмәкәрлек җитәрлек ныклы позицияләр биләвенә карамастан, кайбер проблемалар чишелмичә кала бирә.

Җирлектәге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген тоткарлаучы факторлар булып:

- Инвестицион ресурсларга кыенлыклы рөхсәт, кредит ресурсларының кыенлыгы фонында үз финанс чараларының кимлеге;
- Кече эшмәкәрлек субъектларының гамәлдәге закончалыклардагы үзгәрешләр турында тулы мәгълүматлы булмавы, административ каршылыклар һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген тормышка ашырганда хакимият органнарының төгәл регламетлары булмавы;
- Шәһәрләрнең кече предприятиеләрендә квалификацияле эшче белгечләрнең җитмәве тора.

  Эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары ягыннан мәсьәләләрне кабул итү һәм тормышка ашыру проблемалары булып:

- Кече эшмәкәрлек субъектларының югары булмаган социаль җаваплылыгы(ялланып эшләүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштермәү, хезмәткә түләү фондын түбәнәйтү һәм аны “конверт” формасында түләү, мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе һәм социаль иминиятләштерү закончалыкларын үтәмәү);

- Кече эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлек алып бара торган икътисад тармакларының пропорциясезлеге(сәүдәнең күп үсеше фонында җитештерүнең аз үсеше);

Тимершык авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең алга таба үсеше һәм булган каршылыкларны җиңеп чыгу урыннарда аны үстерү өчен мәгълүмати, белем бирү, консультацион, финанс юнәлешләрендә комплекслы һәм адреслы ярдәм итү, эшлекле контактлар һәм кооперацияне җайлаштыру юлы, шулай ук эшмәкәрләрдә барлыкка килергә мөмкин булган коллектив ихтыяҗлар, башка аспектларда ярдәм итү юлы белән уңайлы шартлар тудырып, максатчан эш алып бару нигезендә генә мөмкин. Программа җирле хакимият органнарының, шулай ук дәүләтнеке булмаган оешмаларның куелган максатка ирешү өчен тырышлыгын берләштерергә һәм оптимизацияләргә мөмкинлек бирә.

3. Программаның социаль-икътисадый эффективлыгының көтелгән бәясе.

Программа Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне алга таба үстерү өчен уңай шартлар булдыруга юнәлтелгән чаралар комплексын үз эченә ала.

Программаны үтәү:

- Районның социаль һәм икътисадый стабильлегенең мөхим элементларының берсе буларак, кече эшмәкәрлекнең тотрыклы эшчәнлеген стимуллаштыручы, уңайлы икътисадый мохит формалаштыруга;
- Кече эшмәкәрлекне үстерү темпларын арттыруга, кече предприятиеләрнең икътисадый ныгуына һәм эшчәнлек өлкәсенең киңәюенә;
- Мәшгульлекнең өстәмә мөмкинлекләре барлыкка килүгә, кече предприятиеләрдә эшләүчеләрнең хезмәт хаклары артуга;
- Товар базарының конкуренциягә сәләтле продукция һәм җирле җитештерү хезмәтләре белән тулылануына;
- Кече эшмәкәрлекнең социаль җаваплылыгы артуына ярдәм итәчәк.

4. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре

Җирлектә яшәүче халыкның яшәү шартларын яхшыртуга юнәлтелгән стабиль икътисадый үсешне тәэмин итү максатында, эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре билгеләнгән:

-авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү;
-халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү;
- транспорт һәм элемтә өлкәсе;
- төзелеш;
- социаль хезмәтләр өлкәсе.

5. Программаның төп чараларына карата эшләнгән юнәлешләр.

1. Кече эшмәкәрлекне эффектлы үстерү өчен административ каршылыкларны киметү һәм хокукый базаны камилләштерү.

2. Кече эшмәкәрлеккә мәгълүмати-консультацион ярдәм итү.

3. Тимершык авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек турында уңайлы иҗтимагый фикер һәм эшмәкәрнең уңай имиджын формалаштыру.

4. Яшьләрнең һәм эшсезләрнең эшмәкәрлек инициативасын хуплау һәм стимуллаштыру.

5. Кече эшмәкәрлек субъектлары арасында, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән хакимият органнары арасында партнерлык мөнәсәбәтләре урнаштыруга булышлык итү.

6. Программаны тормышка ашыру механизмы

| | |
|---|---|
| Программа белән идарә итү | Саба  муниципаль районы Тимершык  авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны финанслау | Бюджеттан тыш чыганаклар, Тимершык  авыл җирлегенең кече һәм урта бизнес субъектларының үз акчалары |
| Программаның төп үтәүчеләре | Саба  муниципаль районы Тимершык  авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту | Саба муниципаль районы Тимершык  авыл җирлеге башкарма комитеты |

7. Тимершык авыл җирлеге буенча 2020-2021 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасының төп чаралары

| № | Чаралар исемлеге | Нәтиҗә | Финанс чыганаклары | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1.Кече эшмәкәрлекне нәтиҗәле үстерү өчен хокукый базаны камилләштерү һәм административ киртәләрне киметү | | | | |
| 1 | Эшмәкәрлектә норматив-хокукый базаны булдыру | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә нәтиҗәле оештыру эшләрен үткәрү | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 2 | Коррупциягә каршы көрәшүдә чараларны камилләштерү турында киңәшләр әзерләү | Коррупциягә каршы үз-үзеңне тотуны гомумиләштерү һәм тарату уңай тәҗрибәсе. Коррупция фактларына каршы эшмәкәрләрнең көрәшен арттыру, бизнес алып баруда этик дәрәҗәсен күтәрү, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мәнфәгатьләрен и хокукларын яклау | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 3 | Сәүдә челтәрләре белән килешүләр эшләү | Ярдәм итү максатыннан эре сәүдә челтәрләре белән җирле товар җитештерүчеләр арасында үзара мөнәсәбәтләрне җайга салу һәм җирле товар җитештерүчеләрнең продукциясен сату мөмкинлекләрен арттыру максатларында | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 2. Эшмәкәрлекне инновацион үстерү(инфраструктураны үстерү, инновацион потенциалны үстерү, инновацион процесска яшьләрне тарту) | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Яшьләрне эшмәкәрлеккә тартучы чаралар комплексы уздыру, шул исәптән укыту, информацион тәэмин итү, конкурслар һәм ярышлар, ярминкәләр уздыру. | Яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә тарту. Яшь белгечләрне эшкә урнаштыру мәсьәләсен өлешчә чишү. | Татарстан Республикасы бюджеты | 2020-2021 еллар |
| 2 | Бизнес-инкубаторларны үстерү | Белем бирү программаларын үстерүдә субсидияләр бирү, трансферт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм технологияләрне коммерцияләштерү, бизнес-инкубация процессларын камилләштерүгә юнәлдерелгән | Татарстан Республикас ы бюджеты | 2020-2021 еллар |
| 3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс-кредит һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү. | | | | |
| 1 | Тимершык авыл җирлеге буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме кысаларында чараларны тормышка ашыруда дәүләт хакимиятенең федераль һәм республика структураларына булышлык итү | Эшмәкәрлекне үстерүгә юнәлтелгән республика һәм федераль программаларда катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 2 | Микрокредитлаштыру институтларын үстерү (кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган программалар нигезендә)) | Өстәмә эш урыннары булдыруга юнәлдерелгән кече эшмәкәрлек субъектларының социаль әһәмиятле инвестицион проектларына конкурс нигезендә ташламалы кредит бирү. | Татарстан Республикас ы бюджеты | 2020-2021 еллар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына инвесторлар эзләүдә булышлык итү | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының потенциаль инвесторлар белән хезмәттәшлеген оештыру, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының инвестицион проектларын гамәлгә ашыру өчен банк финансларын һәм шәхси капиталын җәлеп итү | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 4 | Тимершык авыл җирлеге икътисадының өстенлекле юнәлешләрен үстерү максатында, Тимершык авыл җирлеге буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын җир кишәрлекләре һәм торак булмаган биналар белән тәэмин итүдә булышлык итү | Авыл җирлеге икътисадының өстенлекле юнәлешләрен үстерү максатларында кече предприятиеләрне җир кишәрлекләре, торак булмаган сәүдә һәм җитештерү биналары белән тәэмин итү, районда үткәрелә торган тендерлар, аукционнар турында эшмәкәрләрнең хәбәрдарлыгын арттыру | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 5 | Кече һәм урта бизнес мәнфәгатьләрен берләштерә торган эшмәкәрлек эшчәнлеген алып баруның сыгылмалы финанс технологияләре һәм бер үк вакытта конструктив ысуллары буларак финанс лизингы һәм франчайзинг мөмкинлекләрен нәтиҗәле файдалануга ярдәм итү | Лизинг шартларында заманча җиһазларны, технологияләрне куллану өлешендә кече предприятиеләрнең мөмкинлекләрен киңәйтү, франчайзинг механизмы ярдәмендә бизнесны киңәйтүгә ярдәм итү | Финансларсыз_ | 2020-2021 еллар |
| 6 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларга җәлеп итү һәм стимуллаштыру | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларга җәлеп итү һәм стимуллаштыру | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 4. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә мәгълүмати-консультацион ярдәм күрсәтү | | | | |
| 1 | Районда уздырылучы кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм ярдәм итү өлкәсендә уздырылучы чаралар турында мәгълүмат биреп бару | Кече һәм урта бизнес вәкилләренең алдынгы тәҗрибәләрен җәелдерү һәм системалаштыру. Саба муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан уздырылучы конкурслар, күргәзмәләр һәм | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | башка чараларда катнашуга кече эшмәкәрлек субектларын тарту | | |
| 5. Эшмәкәрнең уңай имиджын һәм кече һәм урта эшмәкәрлек турында уңай җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру | | | | |
| 1 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе территориясендә үткәрелә торган күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, конкурсларда катнашуга җәлеп итү | Эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү, эшкуарлык эшчәнлегенең иң яхшы субъектлары эшенең алдынгы тәҗрибәсен тарату, Тимершык авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешендә кече һәм урта бизнесның ролен һәм әһәмиятен пропагандалау | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 6. Кече һәм урта эшмәкәрлек өчен квалификацияле кадрлар әзерләү | | | | |
| 1 | Белем бирү программаларын үткәрү, шул исәптән квалификация күтәрү, бер тапкыр лекцияләр, стажировкалар, семинарлар (эшмәкәр тарафыннан белем бирү учреждениесен мөстәкыйль сайлап алу һәм укыту юнәлешен сайлап алу максатында сертификатлар бирү принцибы буенча)) | Эшмәкәрләрнең белемлелеген арттыру | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 2 | Законнар үзгәрүгә бәйле рәвештә кече һәм урта эшмәкәрлек мәсьәләләре буенча гамәли семинарлар үткәрү | Сәүдә, көнкүреш һәм башка хезмәтләр күрсәткәндә хокук бозуларны булдырмау максатларында законнардагы үзгәрешләр турында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына хәбәр итү | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 3 | Эшмәкәрләргә социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре, хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү | Хезмәт законнары өлкәсендә эшмәкәрлек структураларының белем дәрәҗәсен күтәрү | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 7. Яшьләрнең һәм эшсезләрнең эшмәкәрлек инициативаларына ярдәм итү һәм стимуллаштыру | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларының Тимершык авыл җирлеге югары уку йортлары һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре белән үзара хезмәттәшлеген оештыру, шәһәр өчен өстенлекле тармакларда инициативалы, җаваплы затларны үз бизнесын (мәшгульлеген) оештыруга җәлеп итү һәм аларга хакимият органнары тарафыннан ярдәм күрсәтү мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү максатларында | Яшьләрнең эшмәкәрлек эшчәнлеген стимуллаштыру, эшкә урнашу проблемалары белән очрашкан гражданнарны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |
| 2 | Эшмәкәрлек эшчәнлеге нигезләре буенча шәхси консультацияләр үткәрү, тренинглар, укыту курслары оештыру | Бизнес алып бару нигезләре турында хокукый грамоталылыкны һәм мәгълүматлылыкны арттыру | Финансларсыз | 2020-2021 еллар |